# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы территориясендә**
**салым салуның патент системасын кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 13 сентябрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон белән Россия Федерациясе Салым кодексының $26^{5}$ бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасы гамәлгә кертелә.

2 статья. **Индивидуаль эшкуарның потенциаль алырга мөмкин булган еллык керем күләмен билгеләү**

Индивидуаль эшкуарның индивидуаль эшкуар эшчәнлегенең физик күрсәткеч берәмлегенә потенциаль алырга мөмкин булган еллык кереме һәм потенциаль алырга мөмкин булган максималь еллык кереме күләмнәре эшкуарлык эшчәнлегенең һәр төре буенча әлеге Законга кушымта нигезендә билгеләнә.

3 статья. **Татарстан Республикасы Законын үз көчен югалткан дип тану**

"Татарстан Республикасы территориясендә патент нигезендә салым салуның гадиләштерелгән системасын индивидуаль эшкуарлар тарафыннан куллану мөмкинлеге турында" 2008 елның 3 октябрендәге 81-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

4 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон 2013 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 29 сентябре
№ 65-ТРЗ

«Татарстан Республикасы территориясендә
салым салуның патент системасын кертү турында»
Татарстан Республикасы Законына кушымта

Эшкуарлык эшчәнлеге төрләре буенча индивидуаль эшкуарның
потенциаль алырга мөмкин булган еллык кереме күләмнәре

| № т/с | Эшкуарлык эшчәнлегенең төре | Физик күрсәткеч* | Татарстан Республикасы территориясендә, халык саны 1 млн. кешедән артыграк булган шәһәрләрдән тыш | | Халык саны 1 млн. кешедән артыграк булган шәһәр территориясендә | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | индивидуаль эшкуар эшчәнлегенең 1 физик күрсәткече берәмлегенә потенциаль алырга мөмкин булган еллык керем күләме (мең сумнарда) | потенциаль алырга мөмкин булган максималь еллык керем күләме (мең сумнарда) | индивидуаль эшкуар эшчәнлегенең 1 физик күрсәткече берәмлегенә потенциаль алырга мөмкин булган еллык керем күләме (мең сумнарда) | потенциаль алырга мөмкин булган максималь еллык керем күләме (мең сумнарда) |
| 1 | Тукыма, мех һәм күн әйберләре, баш киемнәре һәм текстиль галантереясы әйберләре ремонтлау һәм тегү, трикотаж әйберләрне ремонтлау, тегү һәм бәйләү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 2 | Аяк киемнәре ремонтлау, чистарту, буяу һәм тегү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 3 | Чәчтарашлар һәм косметика хезмәтләре күрсәтү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Химик чистарту, буяу һәм кер юу хезмәтләре күрсәтү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 5 | Металл галантереясын, ачкычлар, номер билгеләрен, урамнар күрсәткечләрен ясау һәм ремонтлау | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 6 | Көнкүреш радиоэлектрон аппаратурасын, көнкүреш машиналарын һәм көнкүреш приборларын, сәгатьләрне ремонтлау һәм аларга техник хезмәт күрсәтү, металл әйберләрне ремонтлау һәм ясау | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 7 | Җиһазлар ремонтлау | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 8 | Фотоателье, фото- һәм кинолабораторияләр хезмәтләре күрсәтү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 9 | Автотранспорт һәм мототранс-порт чараларына, машиналарга һәм җайланмаларга техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ре-монтлау | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 540 | 3 000 | 600 | 5 000 |
| 10 | Автомобиль транспортында йөкләр ташу буенча автотранс-порт хезмәтләре күрсәтү | транспорт чарасы | 270 | 3 000 | 600 | 5 000 |
| 11 | Автомобиль транспортында пассажирлар йөртү буенча ав-тотранспорт хезмәтләре | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | күрсәтү | | | | | |
| 11.1 | Такси эшчәнлеге | транспорт чарасы | 250 | 3 000 | 500 | 5 000 |
| 11.2 | Пассажирлар йөртү буенча, такси эшчәнлегеннән тыш, автотранспорт хезмәтләре күрсәтү | транспорт чарасы | 1 000 | 3 000 | 1 800 | 5 000 |
| 12 | Торак һәм башка корылмаларны ремонтлау | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 13 | Монтаж, электромонтаж, санитар-техник һәм эретеп ябыштыру эшләрен башкару хезмәтләре күрсәтү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 14 | Балконнарга һәм лоджияләргә пыяла кую, пыяла һәм көзгеләр кисү, пыяланы сәнгатьчә эшкәртү хезмәтләре күрсәтү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 15 | Халыкны курсларда укыту һәм репетиторлык хезмәтләре күрсәтү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 310 | 5 000 |
| 16 | Балаларны һәм авыруларны карау һәм тәрбия кылу хезмәтләре күрсәтү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 310 | 5 000 |
| 17 | Пыяла савыт һәм икенчел чимал, металл ватыкларыннан тыш, кабул итү хезмәтләре күрсәтү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 18 | Ветеринария хезмәтләре | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 19 | Милек хокукында индивидуаль эшкуарныкы булган торак һәм торак булмаган биналарны, дачаларны һәм җир кишәрлекләрен арендага (наемга) бирү | | | | | |
| 19.1 | Милек хокукында индивидуаль эшкуарныкы булган торак биналарны, дачаларны арендага (наемга) бирү | аренда объекты | 260 | 10 000 | 300 | 10 000 |
| 19.2 | Милек хокукында индивидуаль эшкуарныкы булган торак булмаган биналарны, җир кишәрлекләрен арендага (наемга) бирү | аренда объекты | 2 000 | 10 000 | 3 000 | 10 000 |
| 20 | Халык сәнгать кәсепләре әйберләрен ясау | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 310 | 5 000 |
| 21 | Җитештерүгә кагылышлы башка хезмәтләр күрсәтү (авыл хуҗалыгы продуктларын һәм урман байлыкларын эшкәртү хезмәтләре, шул исәптән ашлык тарттыру, ярмаларны чистарту, орлык маен эшкәртү, колбаса җитештерү һәм каклау, бәрәңге эшкәртү, чимал хәлендәге юылган йонны трикотаж җеп өчен эшкәртү, терлек тиресен | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | эшкәртү, йон тарау, йорт хайваннары йонын алу, агач савыт-сабалар һәм балчыктан әйберләр ремонтлау һәм ясау, бакчаларны, яшелчә бакчаларын һәм яшел үсентеләрне корткычлардан һәм авырулардан саклау; киез аяк киемнәре әзерләү; заказчы материалыннан авыл хуҗалыгы инвентаре ясау; металлга, пыялага, фарфорга, агачка, керамикага чокып бизәк төшерү эшләре; агач көймәләр ясау һәм ремонтлау; уенчыклар ремонтлау; турист кирәк-яракларын һәм инвентарен ремонтлау; яшелчә бакчаларын сөрү һәм утын яру хезмәтләре; күзлек оптикасын ремонтлау һәм ясау хезмәтләре; визит карточкаларын һәм гаилә тантаналарына чакыру билетларын әзерләү һәм бастыру; төпләү, брошюралау, каймалау, катыргы әйберләр ясау эшләре; сифоннар өчен газ баллоннарын тутыру, электрон сәгатьләрнең һәм башка приборларның электр энергиясе белән тәэмин итү элементларын алмаштыру) | | | | | |
| 22 | Келәмнәр һәм келәм әйберләре җитештерү һәм реставрацияләү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | саны | | | | |
| 23 | Ювелир әйберләр, бижутерия ремонтлау | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 24 | Ювелир әйберләрне чүкеп һәм чокып бизәү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 25 | Заказчының сөйләвен, җырлавын, уен коралында уйнавын магнит тасмасына, компакт-дискка монофоник һәм стереофоник яздыру, музыкаль һәм әдәби әсәрләрне магнит тасмасына һәм компакт-дискка күчереп яздыру | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 26 | Торак урыннарны җыештыру һәм йорт хуҗалыгын алып бару хезмәтләре күрсәтү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 27 | Торак урын интерьерын бизәү хезмәтләре һәм сәнгатьчә бизәү хезмәтләре күрсәтү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 28 | Физик культура һәм спорт буенча дәресләр үткәрү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 29 | Тимер юл вокзалларында, автовокзалларда, аэровокзалларда, аэропортларда, диңгез һәм елга | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | портларында багаж ташучы хезмәтләре күрсәтү | | | | | |
| 30 | Түләүле бәдрәф хезмәтләре күрсәтү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 310 | 5 000 |
| 31 | Өйдә ашамлыклар әзерләү буенча пешекче хезмәтләре күрсәтү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 310 | 5 000 |
| 32 | Су транспортында пассажирлар йөртү хезмәтләре күрсәтү | транспорт чарасы | 1 000 | 3 000 | 1 000 | 5 000 |
| 33 | Су транспортында йөк ташу хезмәтләре күрсәтү | транспорт чарасы | 250 | 3 000 | 1 000 | 5 000 |
| 34 | Авыл хуҗалыгы продукциясен урнаштыруга бәйле хезмәтләр (саклау, сортларга аеру, киптерү, юу, фасовкалау, төргәкләү һәм транспортировкалау) | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 35 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе хезмәтләре күрсәтүгә бәйле хезмәтләр (механикалаштырылган, агрохимик, мелиоратив эшләр, транспорт эшләре) | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 36 | Яшел хуҗалык һәм декоратив чәчәкләр үстерү хезмәтләре күрсәтү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 37 | Аучылык хуҗалыгын алып бару һәм ауны гамәлгә ашыру | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 38 | Медицина эшчәнлеге яисә фармацевтика эшчәнлеге белән әлеге эшчәнлек төрләренә лицензиясе булган затның шөгыльләнүе | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 3 000 | 370 | 5 000 |
| 39 | Лицензиясе булган затның хосусый детектив эшчәнлеген гамәлгә ашыруы | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 40 | Прокат хезмәтләре күрсәтү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 41 | Экскурсия хезмәтләре күрсәтү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 42 | Йола хезмәтләре күрсәтү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 3 000 | 370 | 5 000 |
| 43 | Ритуаль хезмәтләр күрсәтү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 3 000 | 370 | 5 000 |
| 44 | Урам патрульләре, сакчы, каравылчы һәм вахтер хезмәтләре күрсәтү | индивидуаль эшкуарны кертеп, хезмәткәрләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 45 | Сәүдә оешмасының һәр объекты буенча сәүдә залы 50 квадрат метрдан артыграк булмаган мәйданлы стационар сәүдә челтәре объектлары аша гамәлгә ашырыла торган ваклап сату сәүдәсе | сәүдә челтәре объекты | 2 500 | 10 000 | 3 450 | 10 000 |
| 46 | Сәүдә заллары булмаган стационар сәүдә челтәре объектлары аша, шулай ук стационар булмаган сәүдә челтәре объектлары аша гамәлгә ашырыла торган ваклап сату сәүдәсе | сәүдә челтәре объекты | 2 500 | 10 000 | 3 450 | 10 000 |
| 47 | Җәмәгать туклануы оешмасының һәр объекты буенча кулланучыларга хезмәт күрсәтү залы 50 квадрат метрдан артыграк булмаган мәйданлы җәмәгать туклануы оешмасы объектлары аша күрсәтелә торган җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү | җәмәгать туклануы оешмасы объекты | 1 200 | 10 000 | 1 950 | 10 000 |

* Индивидуаль эшкуар эшчәнлегенең физик күрсәткеч зурлыгы 1 берәмлектән артык булган очракта, потенциаль алырга мөмкин булган еллык керем күләме индивидуаль эшкуар эшчәнлегенең физик күрсәткеч санына тапкырлап арттырыла һәм әлеге эшчәнлек төре буенча потенциаль алырга мөмкин булган еллык керемнең максималь күләменнән арта алмый.